



# Сибгат Хәким (1911-1986)

Халыктагы тере фикерләрнең
Хәкиме син-тугры хәкиме...



Татарстанның халык шагыйре, публицист, җәмәгать эшлеклесе Сибгат Хәким (Сибгат Таҗи улы Хәкимов) 1911 елның 4 декабрендә Россиянең элекке Казан губернасы Царевококшай өязе (хәзерге Әтнә районы) Күлле Киме авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә.





Авыл мәктәбендә җиде сыйныф тәмамлагач, берникадәр вакыт мәктәптә пионерлар җитәкчесе булып эшли. 1931 елда Казанга килеп, татрабфакта укый башлый.

1937 елда Казан дәүләт педагогия институтының, татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый һәм сугышка чаклы Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторында мөхәррир (1937-1938) һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли.




Сибгат Хәким шагыйрьләр Х.Туфан, Муса Җәлил, Әхмәт Фәйзи, Әхмәт Исхак, Шәйхи Маннур арасында (1940 ел)

- 1941 елның июнендә армиягә чакырылып, шул елның ахырына кадәр запастагы гаскәри берәмлектә хезмәт итә, аннары кыска мөддәтле хәрби курсларны тәмамлап, 1942 елның маеннан хәрәкәттәге армиядә: әүвәл укчы взвод, соңыннан рота командиры сыйфатында Ржев яны һәм Курск тирәсендә барган сугышларда катнаша, фронттагы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. 1944 елның язында Саратов шәһәрендә хәрби-сәяси курсларны тәмамлаганнан соң, 1945 елның маена кадәр Молдавиядәге чик буе гаскәрләренең округ хәрби газетасында инструктор булып хезмәт итә.




Берлинга таба. Сибгат Хәким йөргән юллар.
Рәссам В.С.Климашин.

# Гомеремне аңа багышладым



47 ел бергә гомер иткән тормыш иптәше Мөршидә Вилданова-Хәкимова






Шагыйрь яшәгән йорт

# Гаилә



Сибгат Хәким туганнары белән
(сулдан икенче-әнисе)




Гаиләсе белән. Хатыны Мөршидә, улы Рафаил

Рафаил Сибгат улы Хәкимов – язучы, сәясәтче, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институты мөдире.













Уйчан гына балкып йөрсә дә шул,
Көчле рухлы булган Сибгат ага!
Әле дә булса “Җылы Сүзе” белән
Шигърияткә безнең учак яга.

Л.Шагыйрьҗан





# Мең елдан сон да бер синең, илем, Кайтасыңны беләм Тукайга.





Тукайның кабере янында

Шагыйрь йөри Кырлай урамында
Кырлай каеннарын  сагынып килгән .
Кояш төшкән урман аланында
Котырып үскән чабылмаган үлән.
Гамил Афзал

# Шигырь бәйрәмендә












Җәмәгать эшләре һәм татар әдәбиятын үстерү өлкәсендәге нәтиҗәле хезмәтләре өчен С.Хәким Ленин ордены (1971), Октябрь Революциясе (1981) һәм Хезмәт Кызыл Байрагы (1957) орденнары белән бүләкләнә. Ул 1986 елда вафат була, Казанның Яңа бистә зиратында җирләнә. С.Хәким — 1938 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.



# Китаплары



СИБГАТ ХӘКИМ
СИБГАТ ХӘКИМ
СИБГАТ ХӘКИМ
торыгыз, мусалар!
Сибгат Хаким
Врата времен
Сибгат Хәким
Тукай турында поэмалар
Рафаэль Мустафин
СИБГАТ ХАКИМ
КИСКЕЧ ЖЫРЫ









Курск Дугасындагы сугыш. Сибгат Хәкимнең “Дуга” поэмасы каһарманнары. П.Жигмионт, Н.Присекип.

- 1981 елның 26 декабрендә Сибгат Хәкимнең 70 еллык юбилее уңае белән шагыйрь укыган мәктәпнең бер классында музей-бүлмә ачыла. Бу музей-бүлмә укытучылар, укучылар, авыл халкы, музей җитәкчесе Луиза апа Шәмсиеваның зур тырышлыгы һәм Сибгат Хәкимне хөрмәт итүләре аркасында туа. 1987 елда музейга “мәктәп музее” дигән таныклык (№5894) бирелә. Ә 1995 елның гыйнварында музей дәүләт статусы ала һәм ТР БДН берләшмәсенә алына.
- 1997 елда музейны яңа мәктәпкә күчерәләр. Бу тантанага Татарстан дәүләт Фәннәр академиясеннән бер төркем галимнәр белән Сибгат Хәкимнең улы Рафаэль Хәкимов кайта. Ул музейга 15тән артык документ калдыра, “Сибгат Хәким музее” дигән буклет эшләтә, ә мәктәпкә Сибгат Хәкимнең бюстын бүләк итә. Бу бюст мәктәп фойесында тора һәм кергән һәркемне каршылый.
- Бүген музей бик тулыланды, зурайды. Анда 2400 дән артык экспонат саклана. Шуларның 90 проценты Сибгат Хәким тормышын, иҗатын чагылдыра. Музей ике бүлмәне үз эченә алган. Аның беренчесе тулысы белән Сибгат Хәкимгә, ә икенчесе Күлле-Киме мәктәбен тәмамлаган күренекле шәхесләргә багышланган.


СИБГАТ ХӘКИМ
Халык күңеленең
хәкиме











